ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында

Яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законлы җайга салу, яшьләр проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү, яшьләр өчен закон чыгару эшчәнлеге күнекмәләрен үзләштерүдә шартлар тудыру һәм Россия яшьләр парламентаризмы хәрәкәтендә Татарстан Республикасы яшьләренең катнашуы өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлегенә ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршында Яшьләр парламенты төзергә.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршында Яшьләр парламенты нигезләмәсен расларга (кушымта итеп бирелә).
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршында беренче чакырылыш Яшьләр парламентының беренче утырышы көненнән, күрсәтелгән көнгә кадәр үзенең исемен һәм вәкаләтләрен саклап, үз эшчәнлеген туктата дип билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршында Яшьләр парламенты төзегәндә әлеге карарда билгеләнгән тәртиптә катнашуны тәкъдим итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 11 июле
№ 2983-V ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2019 елның 11 июлендәге
2983-V ДС номерлы карары
белән расланды

# Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты (алга таба – Яшьләр парламенты) яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законнар белән җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (алга таба – Дәүләт Советы) эшчәнлегенә ярдәм итү, яшьләр проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү, яшьләргә закон чыгару эшчәнлеге күнекмәләрен үзләштерү өчен шартлар тудыру һәм Татарстан Республикасы яшьләренең Россия яшьләр парламентаризмы хәрәкәтендә катнашуы максатларында төзелә.

2. Яшьләр парламенты Дәүләт Советы каршындагы киңәшмә һәм консультатив орган булып тора һәм үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмә һәм Яшьләр парламенты регламенты нигезендә иҗтимагый башлангычларда башкара.

3. Яшьләр парламенты чираттагы чакырылыш Дәүләт Советы вәкаләтләре чорына төзелә.

## II. Яшьләр парламентының төп бурычлары

4. Яшьләр парламентының төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларын эшләгәндә яшь гражданнарның инициативаларын тәкъдим итүдә булышлык күрсәтү;

2) яшьләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өлкәсендә законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

3) Дәүләт Советы комитетларының яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы закон проектларын Дәүләт Советы тарафыннан карауга әзерләү эшчәнлегендә катнашу;

4) Дәүләт Советы комитетларының яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнары мониторингын гамәлгә ашыру эшчәнлегендә катнашу;

5) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хокукларын һәм

законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә законнарны гамәлгә ашыруны иҗтимагый тикшереп тору;

6) яшьләр арасында яшьләрнең хокукый культурасын күтәрүгә һәм актив гражданлык позициясен булдыруга юнәлдерелгән агарту һәм аңлату эшләре алып бару;

7) дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге турында яшь гражданнарның фикерләрен өйрәнү;

8) халыкара, гомумроссия, төбәкара, төбәк һәм җирле яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре тәкъдим иткән иҗтимагый әһәмиятле идеяләрне һәм инициативаларны хуплау һәм алга җибәрү, тәҗрибә уртаклашу максатларында алар белән даими хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

9) Россия Федерациясендә яшьләр парламент хәрәкәте системасында Татарстан Республикасы яшьләре мәнфәгатьләрен күрсәтү;

10) Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары каршында оештырылган яшьләр палаталары (парламентлары) белән мәгълүмати хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыру;

11) Яшьләр парламентын төзү максатларына туры килә торган һәм законнарга каршы килми торган башка бурычларны хәл итү.

## III. Яшьләр парламентының составы һәм аны төзү тәртибе

5. Яшьләр парламенты әгъзалары Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче, Яшьләр парламенты әгъзасы буларак вәкаләтләрен раслаган көнгә 18 яшьтән алып 30 яшькә кадәр булган Россия Федерациясе гражданнары булырга мөмкин.

6. Яшьләр парламенты конкурс нигезендә түбәндәгечә төзелә:

1) Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары яшьләрен тәкъдим итүче гражданнар – 45 кеше;

2) билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, устав максатларына шул исәптән яшьләрне үстерү һәм үз урыннарын табу өчен шартлар тудыру, аларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау кертелгән, республика яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләрен, Татарстан Республикасында гомумроссия яшьләр иҗтимагый оешмалары бүлекләрен, республика иҗтимагый һәм коммерцияле булмаган оешмаларын, шулай ук Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында һәм Дәүләт Советында тәкъдим ителгән сәяси партияләрне тәкъдим итүче гражданнар – 35 кеше;

3) Яшьләр парламентына үз-үзен күрсәтү юлы белән сайлану өчен үз кандидатураларын күрсәткән гражданнар – 20 кеше.

7. Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән яшьләр вәкилләреннән төзелә торган Яшьләр парламентының персональ составы, Яшьләр

парламентын төзү буенча конкурс турында әлеге Нигезләмәгә кушымта булып торган Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә торган конкурс нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

8. Яшьләр парламенты составына кертелгән көнгә 30 яше тулмаган булса, Дәүләт Советы депутатлары Яшьләр парламенты әгъзалары булырга мөмкин. Дәүләт Советы депутатларын Яшьләр парламенты составына кертү конкурстан тыш гамәлгә ашырыла.

9. Дәүләт Советы депутаты Яшьләр парламенты составына керү нияте турында гаризаны Яшьләр парламенты Советына җибәрә. Беренче чакырылыш Яшьләр парламенты составына керергә теләүче Дәүләт Советы депутатлары аның составына керү нияте турында гаризаны Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы Советына юллыйлар.

10. Элеккеге чакырылыш Яшьләр парламенты Советы конкурс буенча сайланган 100 кешедән һәм конкурстан тыш составка кертелгән Дәүләт Советы депутатлары саныннан торган Яшьләр парламенты составының йомгаклау санын билгели һәм Яшьләр парламенты әгъзаларының вәкаләтләрен раслый. Беренче чакырылыш Яшьләр парламенты составының йомгаклау санын билгеләү һәм аның әгъзалары вәкаләтләрен раслау Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

11. Яшьләр парламенты составына конкурс нәтиҗәләре буенча кертелгән әгъзаның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, тиешле исемлек буенча чираттагы иң күп тавыш җыйган кандидат Яшьләр парламенты әгъзасына әверелә.

## IV. Яшьләр парламенты эшен оештыру

12. Яшьләр парламентының беренче утырышы элеккеге чакырылыш Яшьләр парламенты Советы тәкъдиме буенча (беренче чакырылыш Яшьләр парламентының беренче утырышы – Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы Советы тәкъдиме буенча) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының яшьләр сәясәте мәсьәләләрен карый торган комитеты тарафыннан чакырыла. Күрсәтелгән Дәүләт Советы комитеты беренче утырыш көнен билгели, аңа Яшьләр парламенты әгъзаларын чакыра, чакырылган кешеләр исемлеген һәм алып бару тәртибен билгели.

13. Яшьләр парламентының беренче утырышын элеккеге чакырылыш Яшьләр парламенты рәисе (беренче чакырылыш Яшьләр парламентының беренче утырышын – Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы рәисе) ачып җибәрә.

14. Беренче утырышта Яшьләр парламенты әгъзалары ачык тавыш бирү юлы белән һәм гади күпчелек тавыш белән Яшьләр парламенты әгъзалары арасыннан рәисне, рәиснең ике урынбасарын, җаваплы секретарьне сайлап

куялар, Яшьләр парламенты Советының санлы составын билгеләләр һәм аның әгъзаларын сайлыйлар, Яшьләр парламенты комиссияләрен төзиләр. Яшьләр парламенты рәисенә кандидатлар үз эшчәнлекләренең программаларын тәкъдим итәргә тиеш.

15. Яшьләр парламенты утырышы, әгәр анда Яшьләр парламенты әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы була.

16. Яшьләр парламенты үз эшчәнлеге юнәлешләре буенча эшче төркемнәр һәм эксперт төркемнәре төзергә, тәкъдимнәр эшләргә һәм кабул итәргә, аларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына җибәрергә хокуклы.

17. Яшьләр парламенты карарлары, әгәр аларга Яшьләр парламенты әгъзаларының билгеләнгән санынннан күпчелеге хуплап тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

18. Яшьләр парламенты Советын Яшьләр парламенты рәисе җитәкли, аның вәкаләтләре Яшьләр парламенты регламенты белән билгеләнә.

19. Яшьләр парламенты Советы түбәндәгеләрне башкара:

1) Яшьләр парламенты һәм аның комиссияләре эшен оештыра һәм координацияли;

2) Яшьләр парламенты регламентын әзерли һәм аны Яшьләр парламенты раславына тәкъдим итә;

3) Яшьләр парламентының чираттагы елга эш планнарын төзи һәм аларны Яшьләр парламенты раславына тәкъдим итә;

4) Яшьләр парламенты регламенты нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

20. Яшьләр парламенты Советы тәкъдиме буенча Яшьләр парламенты әгъзалары Дәүләт Советы депутатларына, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнары депутатларына җәмәгать башлангычларында ярдәмче сыйфатында, Дәүләт Советы комитетлары каршындагы эксперт советлары составына һәм Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары, ведомстволары каршындагы иҗтимагый советлар составына кертү өчен тәкъдим ителергә мөмкин.

21. Яшьләр парламенты комиссияләре үз функцияләре нигезендә эшне оештыра һәм Яшьләр парламенты утырышларында карау өчен тәкъдимнәр һәм карарлар проектларын әзерли.

22. Яшьләр парламенты эшендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы, Дәүләт Советы депутатлары, шулай ук чакыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләре, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнары депутатлары, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары вәкилләре, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган сәяси партияләр һәм иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре, башка

вазыйфаи затлар катнаша ала.

23. Яшьләр парламенты утырышларын оештыру-техник яктан тәэмин итү Дәүләт Советы Аппараты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы каршындагы
Яшьләр парламенты турында
нигезләмәгә
кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы
Яшьләр парламентын төзү буенча конкурс турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентын төзү буенча конкурс (алга таба – конкурс) үткәрүнең гомуми принципларын һәм тәртибен билгели.

2. Конкурс Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты (алга таба – Яшьләр парламенты) составын 100 кеше исәбендә төзү максатларында Яшьләр парламенты турындагы нигезләмәнең 6 пункты нигезендә үткәрелә.

## II. Конкурсны оештыручы

3. Оештыру комитеты (алга таба – Комитет) Конкурсны оештыра һәм үткәрә.

4. Комитет составы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (алга таба – Дәүләт Советы), алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты (беренче чакырылыш Яшьләр парламентын төзү буенча конкурс үткәргәндә – Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы вәкилләре), Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкилләреннән паритет нигездә төзелә.

5. Комитет составы, шул исәптән аның рәисе, алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты карары белән (беренче чакырылыш Яшьләр парламентын төзү буенча конкурс үткәрү комитетына кагылышлы – Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы карары белән) раслана. Комитет исәбендә 9 кешедән ким була алмый.

6. Комитет:

1) конкурста катнашу өчен гаризаларны «Интернет» челтәрендә конкурсның рәсми мәгълүмат ресурсы булып торган http://molparlament. tatar сайтында (алга таба – мәгълүмат сайты) кабул итә;

2) конкурста катнашучылар белән хезмәттәшлек итә;

3) конкурска йомгак ясый;

4) әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

7. Комитет утырышы, әгәр анда Комитетның расланган составы әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы санала.

8. Комитет карары утырышта катнашучылар санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта Комитет рәисенең тавышы хәлиткеч була.

9. Комитет вәкаләтләре Яшьләр парламентының йомгак исәп составы расланганнан соң туктатыла.

## III. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

10. Конкурсны игълан итү, шул исәптән аны үткәрү вакыты турында карар, алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты тарафыннан кабул ителә. Беренче чакырылыш Яшьләр парламентын төзү буенча конкурс игълан итү турында карар Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы тарафыннан кабул ителә.

11. Конкурс игълан итү турында карар, конкурсны үткәрү шартлары һәм сроклары турындагы мәгълүмат Комитет тарафыннан конкурсны игълан итү турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә мәгълүмат сайтына урнаштырыла, шулай ук Дәүләт Советының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтына урнаштыру өчен җибәрелә.

12. Яшьләр парламенты әгъзаларына кандидатлар Яшьләр парламенты турындагы нигезләмәнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

Конкурста яшьләр парламенты әгъзасына кандидатлар сыйфатында кире алынмаган (үтәлеп бетмәгән) суд хөкеме булган, шулай ук Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.3 һәм 20.29 статьяларында каралган административ хокук бозуларны кылган өчен административ җаваплылыкка тартылган (җәлеп ителгән) затлар катнаша алмый.

13. Бәйге этаплап үткәрелә.

14. Конкурсның беренче этабы конкурста катнашырга теләк белдергән гражданнарның үзләрен  тәкъдим итүен үз эченә ала.

15. Гаризалар түбәндәгечә бирелә:

1) Яшьләр парламенты әгъзасына Татарстан Республикасы муниципаль районнарыннан һәм шәһәр округларыннан кандидат буларак яисә үз-үзен тәкъдим итү тәртибендә кандидатурасын чыгарып конкурста катнашырга теләк белдергән  очракта – электрон рәвештә мәгълүмат сайтына;

2) Яшьләр парламенты әгъзасына республика яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләреннән, Татарстан Республикасында гомумроссия

яшьләр иҗтимагый оешмалары бүлекләреннән, устав максатлары шул исәптән яшьләрне үстерү һәм үз урыннарын табу өчен шартлар тудыру һәм аларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау булган республика иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган оешмаларыннан; Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында һәм Дәүләт Советында тәкъдим ителгән сәяси партияләреннән кандидат буларак конкурста катнашырга теләк белдергән очракта – иҗтимагый оешмасына (алга таба – иҗтимагый оешма) язма рәвештә.

16. Гаризага түбәндәгеләр керә:

1) элекке составтагы Яшьләр парламенты карары белән (беренче чакырылыш Яшьләр парламенты составын төзегәндә – Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы карары белән) билгеләнгән форма буенча шәхси гариза;

2) элекке составтагы Яшьләр парламенты карары белән (беренче чакырылыш Яшьләр парламенты составын төзегәндә – Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы карары белән) билгеләнгән форма буенча кандидатның тутырылган анкетасы. Анкетада конкурста катнашу өчен үз кандидатурасын тәкъдим иткән гражданның әлеге Нигезләмәнең 12 пунктындагы таләпләргә туры килүен билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар мәҗбүри рәвештә күрсәтелергә тиеш;

3) гражданның шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирүе.

17. Яшьләр парламентына Татарстан Республикасы муниципаль районнарыннан һәм шәһәр округларыннан кандидат буларак конкурста катнашу өчен гаризалар яшәү урыны буенча бирелә. Конкурсны үткәрү шартларына туры килә торган кергән гаризалар муниципаль районнарның, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары каршында оешкан яшьләр палаталарына (парламентларына) Комитет тарафыннан җибәрелә. Муниципаль районның, шәһәр округының җирле үзидарә органы каршындагы яшьләр палатасы (парламенты) төзелмәгән очракта, тиешле гаризалар карап тикшерү өчен муниципаль район, шәһәр округы вәкиллекле органының яшьләр (яшьләр сәясәте) мәсьәләләрен карый торган эшче органга (даими комиссиягә, комитетка) җибәрелә.

18. Яшьләр палаталары (парламентлары), Яшьләр парламенты әгъзаларына кандидатлардан гаризаларны карау өчен вәкаләтле башка органнар аларның исеменә килгән гаризаларны карый һәм Комитетка кимендә ике гариза җибәрә.

19. Конкурста катнашу өчен Яшьләр парламенты әгъзасына иҗтимагый оешмалардан кандидат буларак конкурста катнашу өчен Комитетка һәр оешмадан бер гариза бирелә, аңа иҗтимагый оешма уставы нигезендә вәкаләт бирелгән органның конкурста катнашу өчен гариза бирүе турында карары беркетелгән булырга тиеш.

20. Конкурста катнашу өчен үз кандидатураларын тәкъдим иткән гражданнарның гаризалары турыдан-туры Комитет тарафыннан кабул ителә.

21. Тәкъдим ителгән (җибәрелгән) гаризалар Комитет тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Комитет гаризаны кабул итү һәм конкурсның киләсе этабында катнашу өчен рөхсәт бирү турында карар кабул итә. Киләсе этапта катнашуга кертелгән кандидат Яшьләр парламенты әгъзасына кандидат (алга таба – кандидат) статусын ала.

22. Конкурсның икенче этабы яшьләрне Яшьләр парламенты составын төзү буенча конкурска җәлеп итү буенча кандидатлар катнашында чаралар үткәрүне үз эченә ала.

23. Комитет кандидатлар катнашында чаралар исемлеген төзи. Һәр кандидат кандидат тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә торган кимендә ике чарада катнашырга тиеш. Кандидат чараларда катнашмаган очракта, Комитет аны конкурста катнашудан төшереп калдыра.

Кандидат үзен хуплату өчен законга каршы килми торган чараларны мөстәкыйль рәвештә үткәрергә хокуклы.

Кандидат үткәрелгән чаралар турында Комитетка хәбәр итә. Мәгълүмат сайтына тиешле мәгълүмат урнаштырылырга тиеш.

24. Өченче этап кандидатлар өчен тавыш бирүне үткәрүдән гыйбарәт.

25. Кандидатлар өчен тавыш бирү «Интернет» челтәрендә https://open.tatarstan.ru/polls/ сайтында (алга таба – тавыш бирү сайты) башкарыла.

26. Тавыш бирүдә Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче 14 – 30 яшьлек Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – тавыш бирүдә катнашучы) катнаша ала.

27. Кандидатлар өчен тавыш бирү түбәндәге исемлекләр буенча гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасы муниципаль районнарыннан, шәһәр округларыннан кандидатлар;

2) иҗтимагый оешмалардан кандидатлар;

3) үз-үзен тәкъдим итүче кандидатлар.

28. Тавыш бирүдә катнашучы чикләнмәгән кандидатлар саны өчен тавыш бирергә хокуклы. Шул ук вакытта муниципаль районнан (шәһәр округыннан) кандидат өчен бары тик Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче тавыш бирүдә катнашучы гына тавыш бирергә хокуклы.

29. Тавыш бирүдә катнашучы кандидатлар өчен бары тик бер тапкыр гына тавыш бирергә хокуклы.

30. Дүртенче этап конкурсның тавыш бирү нәтиҗәләрен ясаудан һәм бастырып чыгарудан гыйбарәт.

31. Муниципаль районнардан, шәһәр округларыннан кандидатлар

исемлеге буенча конкурста җиңүчеләр дип Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлегендә иң күп тавыш җыйган кандидатлар танышла.

32. Иҗтимагый оешмалардан һәм үз-үзләрен тәкъдим итүче кандидатлар исемлекләре буенча конкурста җиңүчеләр дип тавыш бирүдә катнашучыларның иң күп тавышын җыйган тиешенчә 35 һәм 20 кандидат танышла.

33. Тавыш бирү нәтиҗәләре Комитет тарафыннан «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат сайтына, тавыш бирү сайтына, шулай ук Дәүләт Советының рәсми сайтына нәтиҗәләр рәсми чыгарылганнан соң биш эш көне эчендә урнаштырыла һәм яңа Яшьләр парламентын чакыру турында тәкъдим әзерләү өчен алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты Советына (беренче чакырылыш Яшьләр парламентын төзегәндә – Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр Иҗтимагый палатасы советына) тапшырыла.

34. Конкурсны үткәрү вакыты, шул исәптән конкурсның һәр этабы сроклары, конкурсны үткәрү турында карарда билгеләнә. Шул ук вакытта күрсәтелгән срок яңа чакырылыш Дәүләт Советының беренче утырышы көненә яңа чакырылыш Яшьләр парламенты составын төзү буенча конкурс нәтиҗәләрен билгеләүне тәэмин итәргә һәм, гомумән алганда, ике айдан артмаска тиеш. Тавыш бирүне үткәрү срогына Дәүләт Советына сайлауларда тавыш бирү көнен һәм күрсәтелгән көнгә кадәрге көн кертелергә тиеш түгел.

---